БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 18 » март 2022 ел № 151

Балтач муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында

«Татарстан Республикасы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 413 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Балтач муниципаль районы муниципаль китапханәләр, музейлар, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Балтач муниципаль районы муниципаль башкару сәнгате учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга;

3. Балтач муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәне 3 нче кушымта нигезендә расларга;

4. Балтач муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәне 4 нче кушымта нигезендә расларга;

5. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнә торган Татарстан Республикасы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләмен саклап калу һәм алар тарафыннан шул ук квалификация эшләрен башкару шарты белән, әлеге

карар нигезендә хезмәт өчен түләү шартларына күчкәндә гамәлдә булган хезмәт өчен түләү системасы нигезендә түләнә торган хезмәт хакыннан ким булмаска тиеш дип билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2022 елның ______________
_______ номерлы карарына
1 нче кушымта

Балтач муниципаль районы муниципаль китапханәләр, музейлар, музей тибындагы башка учреждениеләр һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль китапханәләр, музейлар, башка музей тибындагы учреждениеләр һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмен һәм шартларын, шулай ук аларны билгеләүнең критерийларын билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

хезмәт өчен түләү системасы - төп окладлар, вазыйфаи окладлар күләмнәрен, шулай ук федераль законнар һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен кертеп, оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартларын һәм күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы;

төп оклад, хезмәт хакының төп ставкасы - компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен исәпкә алмыйча, эшче һөнәре яисә җитәкче, белгеч, техник башкаручы вазыйфасы буенча һөнәри эшчәнлек алып баручы, тиешле һөнәри квалификация төркеменә керүче белгечнең оклады, хезмәт хакы ставкасы;

вазыйфаи оклад - компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен исәпкә алмыйча, ставканы исәпкә алып, билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен хезмәткәрнең календарь айга хезмәте өчен билгеләнгән күләме;

хезмәткәрнең хезмәт хакы (хезмәте өчен түләү) - хезмәткәрнең квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә, сыйфатына һәм шартларына бәйле булган хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен дә кертеп;

компенсация характерындагы түләүләр - компенсация характерындагы өстәп түләүләр һәм өстәмәләр, шул исәптән гадәти (нормаль) булмаган шартларда эшләгән өчен һәм компенсация характерындагы башка түләүләр;

кызыксындыру характерындагы түләүләр - кызыксындыру характерындагы өстәп түләүләр һәм өстәмәләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре.

1.3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль китапханәләр, музейлар, башка музей тибындагы учреждениеләр һәм мәдәни-ял итү учреждениеләре мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең (алга таба - мәдәният хезмәткәрләре) хезмәт хакы (хезмәт өчен түләү) түбәндәгедән чыгып билгеләнә:

хезмәт хакы (вазыйфаи окладлары), хезмәт хакы ставкалары;

компенсация характерындагы түләүләр;

кызыксындыру характерындагы түләүләр.

1.4. Профиль буенча эш стажы артуга, белем алуга яки белем алу турындагы документларны яңадан торгызуга, квалификация категориясе бирелүгә, мактаулы исем бирелүгә, ведомствоның аерым хөрмәт билгеләре белән бүләкләнүгә бәйле рәвештә, хезмәткәрнең еллык яки башка отпускта булган чорда, аның вакытлыча эшкә сәләтсезлеге чорында, шулай ук уртача хезмәт хакы саклана торган башка чорларда хезмәте өчен түләү күләмен үзгәртү хокукы барлыкка килсә, аның хезмәте өчен түләү күләмен үзгәртү күрсәтелгән чорлар тәмамланганнан соң башкарыла.

1.5. Балтач муниципаль районының муниципаль китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләре һәм мәдәни-ял итү учреждениеләре җитәкчеләре:

белем һәм эш стажы турында (билгеле бер вазыйфада эш белгечлеге буенча) документларны һәм башка нигезләрне тикшерәләр, алар нигезендә муниципаль китапханәләрнең, музейларның, башка музей тибындагы учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял учреждениеләренең барлык хезмәткәрләрнең хезмәт хакы ставкалары (вазыйфаи окладлары) күләме билгеләнә;

ел саен муниципаль китапханәләрнең, музейларның, башка музей тибындагы учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял учреждениеләренең барлык хезмәткәрләрнең тарификация исемлекләрен төзиләр һәм раслыйлар;

муниципаль китапханәләрнең, музейларның, башка музей тибындагы учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренең хезмәт хакын вакытында һәм дөрес итеп билгеләү өчен җавап тоталар.

## II. Мәдәният хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү

2.1. Мәдәният хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|
| | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификациясен биреп раслана торган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| "Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Билетлар буенча контролер | 14 726 | - | - |
| Музейны карап тотучы | 14 726 | 17 383 | - |
| "Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Аккомпаниатор | 14 737 | 17 587 | 20 152 |
| Кинотеатрларга, рестораннарга, кафеларга һәм бию мәйданчыкларына хезмәт күрсәтүче оркестр (ансамбль) артисты | 14 737 | 17 587 | 20 152 |
| Ассистентлар: режиссер, дирижер, балетмейстер, хормейстер | 14 737 | 17 587 | 20 152 |
| Дискотеканы алып баручы | 14 737 | 17 587 | 20 152 |
| Билет кассалары мөдире | 14 737 | 17 587 | |
| Костюмнар бүлмәсе мөдире | 14 737 | 17 587 | |
| Аттракционның контролер-утыртучысы | 14 737 | 17 587 | 20 152 |
| Культоештыручы | 14 737 | 17 587 | 20 152 |
| Фильмфондны ремонтлау һәм реставрацияләү участогы мастеры | 14 737 | 17 587 | 20 152 |
| Экскурсияләр оештыручы | 14 737 | 17 587 | 20 152 |
| Режиссер ярдәмчесе | 14 737 | 17 587 | 20 152 |
| Бию кичәсенең җаваплы оештыручысы | 14 737 | 17 587 | 20 152 |
| Түгәрәк, һәвәскәр берләшмә, | 14 737 | 17 587 | 20 152 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| кызыксынулар буенча клуб җитәкчесе | | | |
| "Әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Администратор | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Администратор (өлкән администратор) | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Аккомпаниатор-концертмейстер | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Оркестр артисты | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Артист-вокалист (солист) | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Библиограф | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Китапханәче | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Әйдәп баручы библиограф | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Әйдәп баручы китапханәче | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Китапханәнең, музейның һәм башка шундый учреждениеләрнең һәм оешмаларның әйдәп баручы методисты | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Баш библиограф | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Баш китапханәче | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Аттракцион мөдире | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Тавыш операторы | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Кинооператор | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Лектор (экскурсовод) | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Китапханә, музей һәм башка шундый учреждениеләр һәм оешмалар методисты | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Клуб учреждениесе методисты, халык иҗаты фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте (мәдәнияте һәм ялы) үзәге һәм башка шундый учреждениеләр һәм оешмалар | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Кинопрограммалар төзү буенча методист | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Мөхәррир (музыкаль мөхәррир) | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Китапханә, музей һәм башка | 14 767 | 17 721 | 20 580 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| шундый учреждениеләр һәм оешмалар мөхәррире | | | |
| Клуб учреждениесе, халык иҗаты фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте (мәдәнияте һәм ялы) үзәге һәм башка шундый учреждениеләр һәм оешмалар мөхәррире | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Репертуар буенча редактор | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Иҗат жанрлары буенча белгеч | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Клуб эше методикасы буенча белгеч | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Исәп-саклау документлары буенча белгеч | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Фольклор буенча белгеч | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Экспозиция һәм күргәзмә бүлеге белгече | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Фондларны саклаучы | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Ут кую буенча рәссам | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Рәссам-декоратор | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Рәссам-конструктор | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Рәссам-бизәүче | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Рәссам-сәхнәләштерүче | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Рәссам-реставратор | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Рәссам-скульптор | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Рәссам-фотограф | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| "Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Балетмейстер-сәхнәләштерүче | 14 787 | 18 034 | 20 899 |
| Фондларның баш саклаучысы | 14 787 | 18 034 | 20 899 |
| Баш рәссам | 14 787 | 18 034 | 20 899 |
| Зоопаркның ветеринария лабораториясе мөдире | 14 787 | 18 034 | 20 899 |
| Кино- һәм видеофильмнар прокаты бүлеге (пункт) мөдире | 14 787 | 18 034 | 20 899 |
| Китапханәнең бүлек (сектор) мөдире | 14 787 | 18 034 | 20 899 |
| Мәдәният йорты (сарае) бүлеге (секторы), мәдәният һәм ял | 14 787 | 18 034 | 20 899 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| паркы, халык иҗатының фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте (мәдәнияте һәм ялы) үзәге һәм башка шундый учреждениеләр һәм оешмалар мөдире | | | |
| Зоопарк бүлеге (секторы) мөдире | 14 787 | 18 034 | 20 899 |
| Музей бүлеге (секторы) мөдире | 14 787 | 18 034 | 20 899 |
| Аттракцион техникасын эксплуатацияләү бүлеге мөдире | 14 787 | 18 034 | 20 899 |
| Музейның күчмә күргәзмәсе мөдире | 14 787 | 18 034 | 20 899 |
| Реставрация остаханәсе мөдире | 14 787 | 18 034 | 20 899 |
| Сәнгати бизәү остаханәсе мөдире | 14 787 | 18 034 | 20 899 |
| Тавыш режиссеры | 14 787 | 18 034 | 20 899 |
| Режиссер (дирижер, балетмейстер, хормейстер) | 14 787 | 18 034 | 20 899 |
| Массакүләм тамашалар режиссеры | 14 787 | 18 034 | 20 899 |
| Режиссер-сәхнәләштерүче | 14 787 | 18 034 | 20 899 |
| Клуб формированиесе, һәвәскәр берләшмә, студия, үзешчән сәнгать коллективы, кызыксынулар буенча клуб җитәкчесе | 14 787 | 18 034 | 20 899 |
| Сәнгать җитәкчесе | 14 787 | 18 034 | 20 899 |

2.2. "Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары" һәм "Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары" һөнәри квалификация төркемнәренә кертелмәгән мәдәният хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Һөнәри стандарт нигезендә вазыйфа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда | |
|---|---|---|
| | урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификациясен биреп раслана торган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 |
| Музей предметларын саклаучы | - | 20 580 |
| Музей предметларын исәпкә алу буенча белгеч | 17 721 | 20 580 |

| | | |
|---|---|---|
| Экскурсовод | 17 721 | 20 580 |
| Тәрҗемәче гид | 17 721 | 20 580 |
| Баш саклаучы | - | 20 899 |
| Музейның исәпкә алу бүлеге (секторы) мөдире | - | 20 899 |

“Музейның бүлеге (секторы) мөдире”, “музейның исәпкә алу бүлеге (секторы) мөдире”, “китапханә бүлеге (секторы) мөдире”, “мәдәният йорты (сарае) бүлеге (секторы), мәдәният һәм ял паркы, халык иҗатының фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте (мәдәнияте һәм ялы) үзәге һәм башка шундый ук учреждениеләр һәм оешмалар мөдире”, зоопарк бүлеге (секторы) мөдире”, “кино- һәм видеофильмнар прокаты буенча бүлек (пункт) мөдире”, һәм “сәнгать җитәкчесе” вазыйфалары буенча өстәмә 1,1 гә тигез булган төп окладка арттыру коэффициентны кулланыла.

**III. Мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын формалаштыру тәртибе**

3.1. Мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Od = Ob \times S,$$

биредә:
Od - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;
Ob - әлеге Нигезләмәнең 2 бүлеге нигезендә кабул ителә торган мәдәният хезмәткәрләренең төп оклады күләме;
S - мәдәният хезмәткәре били торган ставкаларның факттагы саны.

3.2. Әгәр биләгән вазыйфа өчен югары белем - бакалавриат яки специалитет яисә магистратура, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, югары белемле затлар биләгән вазыйфлар буенча - бакалавриат яки специалитет яисә магистратура, урта һөнәри белем бирү программалары буенча урта һөнәри белем, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем таләп ителмәсә, урта гомуми белемгә туры килә торган хезмәт өчен түләү разряды билгеләнә.

3.3. Вазыйфага карата квалификация таләпләре белемнең төрле дәрәҗәләрен күздә тоткан очракта, фактта булган белем дәрәҗәсенә туры килә торган хезмәт өчен түләү разряды билгеләнә.

3.4. Белем дәрәҗәсе үзгәргән очракта, мәдәният хезмәткәре окладына тиешле белем алу турында дәүләт үрнәгендәге документ бирелгән вакыттан төзәтмәләр кертергә тиеш.

**IV. Кызыксындыру характерындагы түләүләр**

4.1. Кызыксындыру характерындагы түләүләргә хезмәткәрне сыйфатлы хезмәт нәтиҗәләренә стимуллаштыруга юнәлдерелгән түләүләр, шулай ук башкарылган эш өчен акчалата бүләкләү керә.

4.2. Кызыксындыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:
эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр;
мактаулы исемнәр, муниципаль бүләкләр булган өчен түләүләр;
квалификация категориясе өчен түләүләр;
профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;
башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре;
премия һәм башка кызыксындыру түләүләре.

4.3. Эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр аерым учреждениеләрдә урта, әйдәп баручы звено һәм җитәкчелек составы вазыйфаларының мәдәният, сәнгать һәм кинематография һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Bsd = Od \times Dsd,$$

биредә:
Bsd - эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен түләүләр;
Od - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;
Dsd - эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмәләр күләме.
Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә күләмнәре 1 таблицада китерелгән.

4.4. Әлеге учреждениедә, бүлекчәдә һәм вазыйфада конкрет эш шартларын исәпкә алып, эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмәләр билгеләнә торган мәдәният хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеге, сайланулы

һөнәр берлеге органы (яисә мәдәният хезмәткәрләре мәнфәгатьләрен тәкъдим итәргә вәкаләтле башка орган) белән килештереп, һәр учреждение тарафыннан раслана.

1 таблица

**Эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләрнең тәкъдим ителә торган күләме**

| т/б № | Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмәләр билгеләү нигезе | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Өстәмә күләме, процентлар |
|---|---|---|---|
| 1. | Физик үсешендә тайпылышлар булган затларга хезмәт күрсәтү (сукырлар, чукраклар) | урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 5 |
| | | әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 5 |
| 2. | Милли статусы булган мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләрендә эшләү | әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 30 |
| | | мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары | 30 |
| 3. | Гамәли эштә чит телне куллану | әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 5 |
| | | мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары | 5 |
| 4. | Милли статус булган мәдәният учреждениеләрендә гамәли эштә ике муниципаль телне куллану <*> | әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 10 |
| | | мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары | 10 |

--------------------------------

<*> Милли статусы булган учреждениеләргә "Татарстан Республикасы Милли китапханәсе" дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе, "Татарстан Республикасы Милли музее" дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе керә.

4.5. Мактаулы исемнәр, муниципаль бүләкләр булган өчен түләүләр мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Bpz = Od \times Dpz,$$

биредә:

$Bpz$ - мактаулы исемнәр, муниципаль бүләкләр булган өчен түләү;

$Od$ - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$Dpz$ - мактаулы исемнәр, муниципаль бүләкләр булган өчен өстәмәләр күләме.

4.6. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, муниципаль бүләкләре, Совет Социалистик Республикалары Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә күләме 8 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалары Союзының, Совет Социалистик Республикалары Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә 10 процент тәшкил итә.

Кызыксындыру характерындагы түләүләр бирү өчен булырга тиешле Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалары Союзы, Совет Социалистик Республикалары Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре, муниципаль бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең кушымтасында китерелгән.

4.7. Мактаулы исемнәр, муниципаль бүләкләр булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү мактаулы исем,

дәүләт бүләге бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исемнәре, ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләкләре булган хезмәткәрләргә мактаулы исемнәр, муниципаль бүләкләр булган өчен түләү хезмәткәрнең сайлавы буенча муниципаль бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

4.8. Квалификация өчен түләүләр тариф-квалификация характеристикалары нигезендә һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә аттестация нәтиҗәләре буенча квалификация категорияләрен бирүне күздә тоткан белгечлекләр буенча эшләүче хезмәткәрләргә бирелә. Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Bkk = Od \times Dkk,$$

биредә:
Bkk - квалификация категориясе өчен түләү;
Od - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;
Dkk - квалификация категориясе өчен өстәмә күләме.
Квалификация категориясе өчен өстәмә күләмнәре 2 таблицада китерелгән.
Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясен төзегән орган (учреждение) боерыгындагы дата нигезендә башкарыла.

2 таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Квалификация категориясе | Өстәмә күләме, процентлар |
|---|---|
| Әйдәп баручы звено мәдәният хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| 2 нче квалификация категориясе | 2 |
| 1 нче квалификация категориясе | 4 |
| Югары квалификация категориясе, шулай ук "баш" яки "әйдәп баручы" исемнәре белән билгеләнгән вазыйфалар | 6 |

4.9. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр, профиль буенча эшнең дәвамлылыгына карап, һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Bs = Od \times Ds,$$

биредә:
Bs - профиль буенча эш стажы өчен түләү;
Od - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;
Ds - профиль буенча эш стажы өчен өстәмә күләме.
Профиль буенча стажга өстәмә түләүләр күләме 3 таблицада китерелгән.

3 таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмәләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Стаж буенча төркем | Өстәмә күләме, процентлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |

| | | |
|---|---|---|
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |
| Әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |
| Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |

4.10. Алар буенча эш вакыты вазыйфасы (белгечлеге) буенча эш стажына кертелә торган вазыйфалар (һөнәрләр) исемлеге Татарстан Республикасы мәдәният министры боерыгы белән раслана.

4.11. Эш стажын үзгәрткәндә, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү) стажны раслаучы документлар оешмада булса, эш стажы өчен түләү күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән яисә стажны раслый торган кирәкле документ бирелгән көннән башкарыла.

4.12. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре мәдәният хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә билгеле бер вакытка (ай, квартал, ел) хезмәт нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре күләменә йогынты ясый торган төп критерий булып Татарстан Республикасы мәдәният министры боерыгы белән раслана торган мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик күрсәткечләренә ирешү тора.

4.13. Мәдәният учреждениеләре мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары учреждение җитәкчесе тарафыннан раслана. Мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының конкрет билгеләре һәм түләүләр башкару шартлары учреждение алдында торган бурычлардан чыгып ел саен билгеләнә.

4.14. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре күләме, аларны бирү тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм коллектив шартнамәләр белән билгеләнә.

4.15. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Bk = Od \times Dk,$$

биредә:

Bk - башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре;

Od - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

Dk - башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмәләрнең иң чик күләме.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмәләрнең иң чик күләме 4 таблицада китерелгән.

4 таблица

**Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмәләрнең иң чик күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Өстәмә күләме, процентлар |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары | 14 |

| | |
|---|---|
| Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 28 |
| Әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 38 |
| Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары | 48 |

4.16. Премия һәм башка кызыксындыру түләүләре хезмәткәрләргә юбилей даталары, аерымлык билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, муниципаль бүләкләр алу белән бәйле рәвештә һәм оешманың локаль актларында һәм коллектив шартнамәләрендә билгеләнгән башка нигезләр буенча билгеле бер вакытка (ай, квартал, ел) бер тапкыр билгеләнә.

4.17. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләр һәм мәдәни-ял итү учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм "Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында" 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатыннан мәдәният хезмәткәрләренә төп эш урыны һәм төп вазыйфасы буенча бер тапкыр түләнә торган акчалата бәләкләү бирелергә мөмкин.

4.18. Премияләр һәм башка акчалата бүләкләү түләүләре күләме, бирү тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм коллектив шартнамәләр белән билгеләнә.

## V. Учреждение җитәкчесенең, учреждение җитәкчесе урынбасарының, баш хисапчының хезмәт хакын билгеләү тәртибе

5.1. Учреждение җитәкчеләренең, учреждение җитәкчеләре урынбасарларының һәм баш хисапчыларның хезмәт хакы вазыйфаи окладлардан һәм компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрдән тора.

5.2. Мәдәният учреждениесе җитәкчесенең окладды, хезмәт өчен түләү төркеменә карап, елына бер тапкыр мәдәният учреждениесен оештыручы тарафыннан билгеләнә. Мәдәният учреждениесе җитәкчесенең хезмәте өчен түләү төркеме мәдәният учреждениесе хезмәткәрләренең штат санына карап билгеләнә.

5.3. Учреждение җитәкчеләре урынбасарларының һәм баш хисапчыларының окладлары әлеге учреждениеләр җитәкчеләренең вазыйфаи окладларыннан 20 - 30 процентка түбәнрәк билгеләнә.

5.4. Җитәкчеләрнең хезмәте өчен түләү төркеме, җитәкчеләрнең окладлары күләмнәре 5 таблицада күрсәтелгән.

**Мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренең окладлары**

5 таблица

| Учреждение тибы | Хезмәт өчен түләү буенча төркем | Бер айга оклад күләме, мең сум | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | Хезмәткәрләрнең штат саны, ставкалар | 10,999 га кадәр | 11 дән 30,999 га кадәр | 31 дән 50,999 га кадәр | 51 дән 75,999 га кадәр | 76 дан 150,999 га кадәр | 151 дән 300,999 га кадәр | 301 дән 500,999 га кадәр | 501 дән артык |
| Китапханәләр | | - | 27,0 | 34,0 | 37,5 | 41,0 | 49,0 | 54,0 | - |
| Клублар | | 25,0 | 31,5 | 34,0 | 37,5 | 39,0 | 44,0 | 54,0 | - |
| Музейлар | | 26,5 | 30,5 | 32,0 | 39,0 | 41,0 | 49,0 | 54,0 | - |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Мәдәни-ял итү үзәге | | - | 36,0 | 37,0 | 39,0 | - | - | - | - |
| Җирле радиотапшырулар | | 24,0 | - | - | - | - | - | - | - |
| Киновидеобер ләшмә | | 22,0 | 27,0 | - | - | - | - | - | - |
| Башкалар | | 22,0 | 37,0 | - | 38,0 | 39,0 | - | - | - |

5.5. Компенсация характерындагы түләүләр, Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә раслана торган компенсация характерындагы түләүләр төрләре исемлеге нигезендә, учреждениеләр җитәкчеләре, аларның урынбасарлары һәм баш бухгалтерлары өчен билгеләнә.

## VI. Компенсация характерындагы түләүләр

6.1. Учреждениеләрдә компенсация характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

белгечләргә авыл җирлегендә эшләгән өчен түләүләр;

авыр эшләрдә, зарарлы һәм (яисә) куркыныч һәм хезмәтнең башка махсус шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә түләүләр;

нормадан тайпылган шартларда (төрле квалификациядәге эшләрне башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, тиешле вакыттан тыш эшне башкарганда, төнлә эшләгәндә һәм эшләрне нормадан тайпыла торган башка шартларда башкарганда) эшләгән өчен түләүләр.

6.2. Компенсация характерындагы түләүләр, аларның күләмнәре һәм аларны гамәлгә ашыру шартлары хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар нигезендә коллектив шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар белән билгеләнә.

6.3. Белгечләргә авыл җирендә эшләгән өчен түләүләр мәдәният хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Bsm = Dsm \times S,$$

биредә:

Bsm - белгечләргә авыл җирендә эшләгән өчен түләү;

Dsm - белгечләргә авыл җирендә эшләгән өчен түләү күләме, ул 1 388,5 сумга тигез дип билгеләнгән;

S - мәдәният хезмәткәре били торган ставкаларның факттагы саны.

6.4. Авыр эшләрдә, зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка махсус хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләргә һәм нормадан тайпылган шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, тиешле вакыттан күбрәк эшләгән өчен, төнлә һәм нормадан тайпылган башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_d \times D_{kh} \times \frac{H_{fsd}}{H_n},$$

биредә:

Bkh - компенсация характерындагы түләүләр;

Od - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладының;

Dkh - компенсация характерындагы түләүгә өстәмә күләме;

Hfsd - законда компенсация характерындагы түләүләр каралган фактта эшләнгән вакыт;

Hn - Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган мәдәният хезмәткәрләренең хезмәт хакының төп ставкасы (төп оклады) өчен сәгать нормасы.

6.5. Нормадан тайпылган шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, тиешле вакыттан күбрәк эшләгән өчен, төнлә һәм нормадан тайпылган башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен түләүләр түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

төнге вакытта һәр эш сәгате нормаль шартларда эшләү белән чагыштырганда артыграк күләмдә, әмма Россия Федерациясе законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән күләмнәрдән киметмичә түләнә;

хезмәткәрне аңа график белән билгеләнгән ял көнендә яисә эш көне булмаган бәйрәм көнендә эшкә җәлеп иткән очракта, эш кимендә икеләтә күләмдә түләнә;

вазыйфаи оклад алучы хезмәткәрләргә эш ял һәм эш көне булмаган бәйрәм көнендә эш вакытының айлык нормасы чикләрендә башкарылса - окладтан тыш кимендә бер көнлек яки сәгатьлек төп ставкасы күләмендә һәм, әгәр дә эш айлык нормадан артык башкарылган булса - төп окладтан тыш кимендә ике сәгатьлек яки көнлек ставка күләмендә түләнә.

6.6. Ял көнендә һәм эш көне булмаган бәйрәм көнендә эшләгән хезмәткәр теләге буенча башка ял көне бирелергә мөмкин. Бу очракта эш көне булмаган бәйрәм көнендәге эш гадәти күләмдә түләнә, ә ял көне өчен түләнми.

6.7. Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү нормаль хезмәт шартлары булган эшләрнең төрле төрләре өчен билгеләнгән окладлар (вазыйфаи окладлар), хезмәт хакы ставкалары белән чагыштырганда югарырак күләмдә, хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә төп окладның кимендә 4 проценты күләмендә билгеләнә.

6.8. Авыр эшләр, зарарлы, куркыныч һәм башка аерым хезмәт шартлары булган эшләр исемлеге, социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча Россия өчьяклы комиссиясе фикерен исәпкә алып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

## VII. Балтач муниципаль районы муниципаль китапханәләренең, музейларының, башка музей тибындагы учреждениеләренең һәм мәдәни-ял учреждениеләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм куллану тәртибе

7.1. Муниципаль китапханәләрнең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру финанс чыгымнары, кулланучылар һәм хезмәт күрсәтүләр саны нормативы нигезендә билгеләнгән агымдагы финанс елына мәдәният учреждениесе акчалары күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм мәдәният учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагыла.

7.2. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән вазыйфаи окладларны, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне исәпләү муниципаль китапханәләрнең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренә агымдагы финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында хезмәт өчен түләүгә каралган акчалар исәбеннән башкарыла.

7.3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль китапханәләренең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәт өчен түләү фондын экономияләү, финанс ягыннан тәэмин итүнең барлык чыганаклары, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, тиешле чорда (ай, квартал, ел) Балтач муниципаль районы муниципаль китапханәләренең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең әлеге Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру түләүләренә юнәлдерелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фонды экономиясе булганда, кызыксындыру түләүләре хезмәт өчен түләү фонды экономиясе барлыкка килгән вазыйфаларның һөнәри-квалификация төркеме хезмәткәрләренә башкарыла.

Хезмәт нормаларын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль китапханәләре, музейлары, башка музей тибындагы учреждениеләр һәм мәдәни-ял учреждениеләре эшчеләренең гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфалары хезмәткәрләренә тиешле чор өчен хезмәт өчен түләү фондын экономияләү хисабына башкарылган акчалата бүләкләү түләве күләме, бу чорда үтәгән эш вакыты нормасын исәпкә алып, «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы федераль закон белән агымдагы елның 1 гыйнварына билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең минималь күләмен өчләтә арттырган күләмнән артып китә алмый.

Хезмәт өчен түләү фондын экономияләү исәбенә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләре һәм мәдәни-ял итү учреждениеләре җитәкчеләренә кызыксындыру түләүләре күләме Балтач муниципаль районының муниципаль китапханәләрен, музейларын, музей тибындагы башка учреждениеләрне һәм мәдәни-ял итү учреждениеләрен оештыручы тарафыннан билгеләнә.

Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, финанс ягыннан тәэмин итүнең барлык чыганаклары хисабына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләре һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәт өчен түләү фондын экономияләү өчен җаваплылык Балтач муниципаль районының муниципаль китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләре һәм мәдәни-ял итү учреждениеләре җитәкчеләренә йөкләнә.

.

Балтач муниципаль районының муниципаль
китапханәләр, музейлар, башка музей тибындагы
учреждениеләр һәм мәдәни-ял учреждениеләре
мәдәният, сәнгать һәм кинематография
хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри
квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең
хезмәте өчен түләү шартлары турында
нигезләмәгә
кушымта

**Кызыксындыру характерындагы түләүләр бирү өчен булырга тиешле Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалары Союзы, Совет Социалистик Республикалары Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикалар мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре исемлеге**

| т/б № | Мактаулы исеме, дәүләт бүләге атамасы |
|---|---|
| 1 | |
| 1. Россия Федерациясе мактаулы исемнәре | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең Халык артисты |
| 1.2. | Россия Федерациясенең Халык рәссамы |
| 1.3. | Россия Федерациясенең Атказанган артисты |
| 1.4. | Россия Федерациясенең Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 1.5. | Россия Федерациясенең Атказанган рәссамы |
| 2. Татарстан Республикасы мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре | |
| 2.1. | Татарстан Республикасының Халык артисты |
| 2.2. | Татарстан Республикасының Халык язучысы |
| 2.3. | Татарстан Республикасының Халык шагыйре |
| 2.4. | Татарстан Республикасының Халык рәссамы |
| 2.5. | Татарстан Республикасының Атказанган артисты |
| 2.6. | Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 2.7. | Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1. | Совет Социалистик Республикалар Союзының Халык артисты |
| 3.2. | Совет Социалистик Республикалар Союзының Халык рәссамы |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре . | |
| 4.1. | Атказанган пропагандачы |
| 4.2. | Халык артисты |

| | |
|---|---|
| 4.3. | Атказанган артист |
| 4.4. | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 4.5. | Халык рәссамы |
| 4.6. | Атказанган рәссам |
| 4.7. | Халык язучысы |
| 4.8. | Атказанган язучы |
| 4.9. | Халык шагыйре |
| 4.10. | Халык җырчысы |
| 4.11. | Халык акыны |
| 4.12. | Атказанган журналист |
| 4.13. | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.14. | Атказанган мәдәни-агарту эшләре хезмәткәре |
| 4.15. | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 4.16. | Атказанган китапханәче |
| 4.17. | Кулланма сәнгать остасы |
| 4.18. | Атказанган халык иҗаты остасы |
| 4.19. | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре<br>. | |
| 5.1. | Атказанган төзүче |
| 5.2. | Халык артисты |
| 5.3. | Атказанган артист |
| 5.4. | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 5.5. | Халык рәссамы |
| 5.6. | Атказанган рәссам |
| 5.7. | Халык язучысы |
| 5.8. | Атказанган язучы |
| 5.9. | Халык шагыйре |
| 5.10. | Атказанган журналист |
| 5.11. | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 5.12. | Атказанган китапханәче |
| 5.13. | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |

| | |
|---|---|
| 5.14. | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 5.15. | Атказанган фән эшлеклесе |

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
карарына
2 нче кушымта

**Балтач муниципаль районының мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Балтач муниципаль районының мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында әлеге Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр шартларын һәм күләмен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

хезмәт өчен түләү системасы - төп окладлар, вазыйфаи окладлар күләмнәрен, шулай ук федераль законнар һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен кертеп, оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартларын һәм күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы;

төп оклад, хезмәт хакының төп ставкасы - компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен исәпкә алмыйча, эшче һөнәре яисә җитәкче, белгеч, техник башкаручы вазыйфасы буенча һөнәри эшчәнлек алып баручы, тиешле һөнәри квалификация төркеменә керүче белгечнең окладу, хезмәт хакы ставкасы;

вазыйфаи оклад - компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен исәпкә алмыйча, ставканы исәпкә алып, билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен хезмәткәрнең календарь айга хезмәте өчен билгеләнгән күләме;

хезмәт хакы (хезмәткәрнең хезмәте өчен түләү) - хезмәткәрнең квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә, сыйфатына һәм шартларына бәйле булган хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм кызыксындыру түләүләре;

компенсация характерындагы түләүләр - компенсация характерындагы өстәп түләүләр һәм өстәмәләр, шул исәптән гадәти (нормаль) булмаган шартларда эшләгән өчен һәм компенсация характерындагы башка түләүләр;

кызыксындыру характерындагы түләүләр - кызыксындыру характерындагы өстәп түләүләр һәм өстәмәләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре.

1.3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең (алга таба - башкарма сәнгать хезмәткәрләре) хезмәт хакы (хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

хезмәт хакы (вазыйфаи окладлары), хезмәт хакы ставкалары;

компенсация характерындагы түләүләр;

кызыксындыру характерындагы түләүләр.

1.4. Профиль буенча эш стажы артуга, белем алуга яки белем алу турындагы документларны яңадан торгызуга, квалификация категориясе бирелүгә, мактаулы исем бирелүгә, ведомстволның аерым хөрмәт билгеләре белән бүләкләнүгә бәйле рәвештә, хезмәткәрнең еллык яки башка отпускта булган чорда, аның вакытлыча эшкә сәләтсезлеге чорында, шулай ук уртача хезмәт хакы саклана торган башка чорларда хезмәте өчен түләү күләмен үзгәртү хокукы барлыкка килсә, аның хезмәте өчен түләү күләмен үзгәртү күрсәтелгән чорлар тәмамланганнан соң башкарыла.

1.5. Балтач муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре:

муниципаль башкару сәнгате учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренең хезмәт хакы (вазыйфаи окладлары) күләмнәрен билгели торган белеме һәм эш (билгеле бер вазыйфада белгечлек буенча эш) стажы турында документларны һәм башка нигезләрне тикшерәләр;

ел саен муниципаль башкару сәнгате учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренә тарификация исемлекләре төзиләр һәм раслыйлар;

муниципаль башкару сәнгате учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмен вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җавап тота.

## II. Башкару сәнгате хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү

| Вазыйфа исеме | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|
| | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификациясен биреп раслана торган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| "Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Театрларның һәм концерт оешмаларының ярдәмче составы артисты | 14 726 | - | - |
| Циркта номер ассистенты | 14 726 | - | - |
| Билетлар буенча контролер | 14 726 | - | - |
| "Урта звено башкару сәнгате хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | | | |
| Кинотеатрларга, рестораннарга, кафеларга һәм бию мәйданчыкларына хезмәт күрсәтүче оркестр (ансамбль) артисты | 14 737 | 17 587 | - |
| Циркта хайваннарны өйрәтүче (дрессировщик) | 14 737 | 17 587 | - |
| Билет кассалары мөдире | 14 737 | 17 587 | - |
| Суфлер | 14 737 | 17 587 | - |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | | | |
| Цирк балеты артисты | 14 737 | 17 587 | 20 152 |
| Ассистентлар: режиссер, дирижер, балетмейстер, хормейстер | 14 737 | 17 587 | 20 152 |
| Костюмнар бүлмәсе мөдире | 14 737 | 17 587 | - |
| Режиссер ярдәмчесе | 14 737 | 17 587 | 20 152 |
| Сөйләм техникасы буенча репетитор | 14 737 | 17 587 | 20 152 |
| "Әйдәп баручы звено башкару сәнгате хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | | | |
| Аккомпаниатор- | 14 767 | 17 721 | 20 580 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| концертмейстер | | | |
| Хор артисты - музыкаль комедия (оперетта) тетрларында , музыкаль-драматик, драма театрларында, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, циркларда | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | | | |
| Администратор, өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән администраторлардан тыш | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Артист - һава гимнасты | 14 767 | 17 721 | - |
| «Эквилибр» жанры артисты | 14 767 | 17 721 | - |
| Хайваннар өйрәтү (дрессурасы) жанры артисты | 14 767 | 17 721 | - |
| жонглирлау жанры артисты | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Иллюзия жанры артисты | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Атлар өйрәтү (дрессурасы) жанры артисты | 14 767 | 17 721 | - |
| Келәм артисты, тамаша (буффонад) клоуны, музыкаль эксцентрик, сатирик | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Җыр һәм бию ансамбльләре оркестры артисты | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Спорт-акробатика жанры артисты | 14 767 | 17 721 | - |
| Опера һәм балет театрларында хор артисты | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Эстрада оркестры (ансамбль) артисты - өченче - бишенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән артистлардан тыш, оркестрның барлык артистлары | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Артистлар - артист - ярдәмче составтагы концерт башкаручыларыннан тыш, концерт башкаручылары (барлык жанрлар) | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Тавыш операторы | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Репертуар буенча редактор | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Балет буенча репетитор | 14 767 | 17 721 | 20 580 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Вокал буенча репетитор | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | | | |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия (оперетта) театрларында, музыкаль-драматик, драма театрларында, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, циркларда, концерт оешмаларында администратор, өлкән администратор | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Курчак театры артисты (курчак уйнатучы) | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Балет артисты | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Җыр һәм бию ансамбле балеты, бию коллективы артисты | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Драма артисты | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
| Оркестр артисты | 14 767 | 17 721 | 20 580 |
